ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 132-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 132-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2025 елның 24 декабре
№ 509-VII ДС

Проект

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2025 № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3) социаль хезмәт күрсәтү йорты, шул исәптән балалар өчен социаль хезмәт күрсәтү йорты;»;

2) 8 статьяның 8 өлешендәге 6 пунктта «психик тайпылышлары булган гражданнар, шул исәптән психик тайпылышлары булган балалар өчен интернат йортларда» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү йортларында, шул исәптән балалар өчен социаль хезмәт күрсәтү йортларында» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, аларның структур бүлекчәләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2025 елның 14 маендагы 305н номерлы боерыгы белән расланган Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, аларның структур бүлекчәләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләре һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының якынча номенклатурасын раслау турында» 2020 елның 17 декабрендәге 918н номерлы боерыгы белән расланган Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының якынча номенклатурасы нигезендә эшләнде.

Закон проектында, югарыда күрсәтелгән боерыкка нигезләнеп, Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары номенклатурасындагы «психик тайпылышлары булган гражданнар, шул исәптән психик тайпылышлары булган балалар өчен интернат йорт» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү йорты, шул исәптән балалар өчен социаль хезмәт күрсәтү йорты» сүзләренә алмаштырырга дип тәкъдим ителә.

Учреждениеләрнең исеменә үзгәреш кертү әлеге учреждениеләр хезмәткәрләренең ташламаларына һәм пенсия белән тәэмин ителешенә йогынты ясамаячак (Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2025 елның 18 апрелендәге 26-5/10/В-7017 номерлы хаты).

---

**«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәреш кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

## ИСЕМЛЕГЕ

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарын үз көчен югалткан дип тануны, туктатып торуны, аларга үзгәреш кертүне яки аларны кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарларына үзгәрешләр кертү таләп ителәчәк:

«Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 ел, 31 декабрь, 915 нче;

«Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 ноябрь, 908 нче;

«Социаль хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен һәм аны алу тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 ноябрь, 927 нче;

«Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче;

«Психик тайпылышлары булган инвалидларга бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү турында» 2022 ел, 19 декабрь, 1366 нчы;

«2023 – 2026 елларда коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан психик тайпылышлары булган инвалидларга бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү» пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2023 ел, 18 июль, 860 нчы.

**«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.

___